СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Карар** **Решение**

№12-34 от «23» июля 2019 г.

Мамадыш муниципаль район Советының «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы милкендә булган объектларның туктатылган яки (һәм) башкарылмаган төзелеш буенча чыгымнарны һәм төп фондларны исәптән чыгару тәртибе турында Нигезләмә хакында» 2018 елның 29 июнендә кабул ителгән 12-27 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Мамадыш муниципаль район Советының «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы милкендә булган объектларның туктатылган яки (һәм) башкарылмаган төзелеш буенча чыгымнарны һәм төп фондларны исәптән чыгару тәртибе турында Нигезләмә хакында» 2018 елның 29 июнендә кабул ителгән 12-27 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында Мамадыш районы прокурорының 2019 елның 7 июнендәге 02-01-08-02-2019 санлы протестын караганнан соң ,Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1.Мамадыш муниципаль район Советының «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы милкендә булган объектларның туктатылган яки (һәм) башкарылмаган төзелеш буенча чыгымнарны һәм төп фондларны исәптән чыгару тәртибе турында Нигезләмә хакында» 2018 елның 29 июнендә кабул ителгән 12-27 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Нигезләмәнең 3-6 пунктларында санап үтелгән документлар нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы милкендә булган объектларның туктатылган яки (һәм) тормышка ашмаган төзелеше буенча төп фондларны һәм чыгымнарны исәптән чыгару мөмкин түгел икән, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы милкендә булган объектларның туктатылган яки (һәм) тормышка ашмаган төзелеше буенча чыгымнарны һәм төп фондларны исәптән чыгару комиссиясе (алга таба - Комиссия) өстәмә документлар (техник экспертиза, эксперт бәяләмәләре) тапшыру турында нигезле запрос җибәрә.”

1.2.Нигезләмәнең 8 пунктындагы 1 абзацында “муниципаль милекне исәптән чыгаруда комиссия тарафыннан түбәндәге очракларда кире кагылырга

000070

мөмкин:” сүзләрен “Комиссия түбәндәге очракларда муниципаль милекне исәптән чыгарудан баш тарта:” сүзләре белән алыштырырга.

2. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районы рәсми сайтында, “Интернет” мәгълүмати- коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр Порталында http://mamadysh.tatarstan.ru/ веб- адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo. tatarstan.ru) игълан итәргә.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Мамадыш муниципаль районы Советының Регламент, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Район Башлыгы,
муниципаль район
Советы рәисе А.П.Иванов